**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯМАШИРМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ямаширмә авылы, Совет ур., 5

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЯМАШУРМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Ямашурма, ул.Советская, 5

тел./факс 8(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР**
**08 ноябрь 2019 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 117**

**Бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге башкарма комитетының хәрби-исәптә булучы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәткә түләүне тәртиптә тоту максатыннан Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының 2019 елның 18 нче апрелендәге 03-16/2920 номерлы хаты нигезендә, 2019 елның 1 нче апреленнән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында авыл җирлекләренең баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәтенә яңа система кертү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгәннәрне расларга:

Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге бухгалтерларының хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) (1 нче кушымта);

Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге хәрби-исәптә булган хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) (2 нче кушымта).

2. Хезмәткәрләрнең әлеге карар нигезендә билгеләнән торган хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре күләме һәм шул ук классификациядәге эшләрне башкару сакланган хәлдә, 2019 елның 31 мартына аларга түләнелә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен конрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ямаширмэ авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.К.Мухтаров

1 нче кушымта
Расланган
Биектау муниципаль районы
Ямаширмэ авыл җирлеге Башкарма
комитеты карары белән
08.11.2019 № 117

Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының хезмәтенә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) түләү шартлары турында
нигезләмә

1. Әлеге Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (алга таба – бухгалтерлар) хезмәтенә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) түләү шартлары турында Нигезләмә бухгалтерларның эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнәнләр:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән күбрәк |
| Баш бухгалтер | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Бухгалтер | | 14 500 сум |

Бухгалтерларга билгеләнәнләр:

1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр дә бухгалтерларга календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнелә, эштән азат ителгән очракта – ахыргы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнелә.

Беренче эш елында еллык түләүле ял биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елда эшкә кергән көннән 31 декабрьгә кадәр исәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) Премияләр бер тапкыр, ай саен, квартал саен һәм еллык эшләү нәтиҗәләре буенча, дәүләт бәйрәмнәре белән бәйле рәвештә, учреждение җитәкчесе карары буенча түләнелергә мөмкин.

4. Бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула нигезендә исәпләп табыла:

$$FOT = \sum_{1}^{n}\left((O_d + 0{,}3 * O_d) * k\right) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t);$$

монда:

$FOT$ – бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - бухгалтерның вазыйфаи окладларын түләү өчен бер айга акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$ – тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, матди ярдәм түләүгә акчалар суммасы;

P – бухгалтерларның еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган*);

$n$ – бухгалтерларның штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү хисаплау.

2 нче кушымта
Расланган
Биектау муниципаль районы
Ямаширмэ авыл җирлеге Башкарма
комитеты карары белән
08.11.2019 № 117

Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге хәрби-исәптә булган хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) хезмәтенә түләү турында
Нигезләмә

Хәрби-исәптә торган хезмәткәрнең хезмәт хакы вазыйфаи оклад, компенсацион түләүләр һәм стимуллаштыручы характердагы түләүләрдән тора.

Хәрби-исәптә торган хезмәткәрнең вазыйфаи окладының күләме Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә "инспектор" вазыйфасы белән билгеләнә һәм 6552,00 сумны тәшкил итә.

Компенсацион түләүләр аерым климатик шартлар белән җирлекләрдә эшләгән өчен түләүләрне үз эченә ала. Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә, хәрби-исәптә булган хезмәткәрнең Татарстан Республикасы өчен хезмәт хакына район коэффициенты күләме 1,15 не тәшкил итә.

Хәрби-исәптәге хезмәткәрләргә стимуллаштыручы характердагы түләүләргә керәләр:

- Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладларга 5 тән 40% ка кадәр күләмдә:

| эш стажы булганда | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан артык | 5 |
| 2 елдан артык | 10 |
| 3 елдан артык | 15 |
| 5 елдан артык | 20 |
| 10 елдан артык | 30 |
| 15 елдан артык | 40 |

- вазыйфаи йөкләмәләрне намуслы итеп башкарган өчен акчалата бүләкләү, елга 2 вазыйфаи окладка кадәр;

- расланган хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре өчен премиял (ай, квартал, ел).